ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 5 20 ноябрь 2024 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мокшино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2024 елның 20 ноябрендә Иске Мокшино авыл клубы бинасында (ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Мокшино авылы, Зеленая урамы, 1 йорт) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мокшино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә , алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтүгә ризамы

Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

• Иске Мокшино авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юлларын чокырларда ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-эшләр өчен шартнамә буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

• Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган скважиналарның су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен павильон төзү, су белән тәэмин итү корылмаларының санитария саклау зонасын койма белән әйләндереп алу, насос сатып алу, товарлар, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр) Иске Мокшино авылында

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

• Иске Мокшино авылы торак пункты территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияләрне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күплəп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ